Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

КАРАР

№27-1 24.10.2022

ТР Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 14 декаберендәге 40 номерлы карары белән расланган Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламентка үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитетының 2021елның 14 декаберендәге 40 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.10 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган тәкъдимнәрдә катнашучы оешмалар һәм вәкаләтле экспертлар тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелә торган хезмәтләрисемлеге.

1.2. 3.3.2.1 пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Формалаштырылган гарызнамәнең формаль-логик тикшерүе гариза бирүченең һәр кырын электрон формадагы кырны тутыру процессында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан тутырылган электрон формадагы электрон кыр ачыкланганда, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм анны мәгълүмат ихәбәр итү юлы белән сорауның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.».

1.3. Административ регламентны түбәндәге эчтәлекле 3.4.1 бүлек өстәргә:

«3.4.1. Муниципаль хезмәтне алданук (актив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда бирү каралмаган.».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе
Әҗмәр авыл җирлеге: Р.М.Вәлитов